ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.07.2026 Олы Кайбыч ав. № 344

2035 елга кадәр чорга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген җылылык белән тәэмин итү схемасын раслау турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

Халыкның уңай тормыш шартларына хокукларын үтәү максатларында «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 2035 елга кадәр чорга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген җылылык белән тәэмин итү схемасын раслау турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә (кушымта).

2. 2035 елга кадәр чорга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген җылылык белән тәэмин итү схемасын раслау турында карар проекты буенча гавами тыңлауларны 2026 елның 30 июлендә 11.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт адресы буенча урнашкан Иҗтимагый үзәк бинасында уздырырга.

3. 2035 елга кадәр Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген җылылык белән тәэмин итү схемасын раслау турындагы карар проектында булган материаллар (текстлы һәм график өлеш) белән эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин:

- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт, 2 кат, 209 кабинет адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге;
- Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге.

3.1. 2035 елга кадәр Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген җылылык белән тәэмин итү схемасын раслау турында карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җыю урыны итеп Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт, 2 кат, 209 кабинет адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеген билгеләргә.

4. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә:

- 2035 елга кадәр Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген җылылык белән тәэмин итү схемасын раслау турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга;

әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Ю.В. Гайнуллинага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026е. 21.07.______ 344 номерлы
Карарына кушымта

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**ПРОЕКТ**

________ с. Большие Кайбицы №_______

Об утверждении схемы теплоснабжения муниципального образования «Большекайбицкое сельское поселение» Кайбицкого муниципального района Республики Татарстан на период до 2035 года

Согласно п.п.6 п.1 ст.6 Федерального закона от 27.07.2010 №190-ФЗ «О теплоснабжении», постановления Правительства РФ от 22.02.2012№ 154 «О требованиях к схемам теплоснабжения, порядку их разработки и утверждения», Исполнительный комитет Кайбицкого муниципального района Республики Татарстан ПОСТАНОВЛЯЕТ:

1. Утвердить схему теплоснабжения муниципального образования «Большекайбицкое сельское поселение» Кайбицкого муниципального района Республики Татарстан на период до 2035 года согласно приложению.
2. Опубликовать настоящее постановление на официальном портале правовой информации Республики Татарстан по веб-адресу: http://pravo.tatarstan.ru и на официальном сайте Кайбицкого муниципального района Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети Интернет по веб-адресу: http://kaybici.tatarstan.ru.
3. Контроль за исполнением настоящего постановления оставляю за собой.

Руководитель А.Н. Макаров